Школьный учебник
«Татарский язык»

КҮҢЕЛЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ

Р.З.Хайдарова, Г.М.Ахметзянова, Л.А.Гиниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ



## 3 класс

ИКЕНЧЕ КИСӘК

издательство
«Татармультфильм»


А
Ә
З
Г
Б
Н
Ж
Ң
Ү
Ө
Я
В
Ә


м
е
ч
ж
з
д
ә
мәктәп



И З Д А Т Е Л Ь С Т В О
**«Татармультфильм»**

Р.З.Хәйдәрова, Г.М.Әхмәтҗанова, Л.Ә.Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## ӨЧЕНЧЕ СЫЙНЫФ

БАШЛАНГЫЧ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ
ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК
(РУС ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЛӘРЕНДӘ)

ДӘРЕСЛЕК Е.И.ПАССОВНЫҢ
КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ КОНЦЕПЦИЯСЕНӘ НИГЕЗЛӘНӘ

Ике кисәктә

2 НЧЕ КИСӘК

КАЗАН
«ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ» НӘШРИЯТЫ
2021

Р.З.Хайдарова, Г.М.Ахметзянова, Л.А.Гиниятуллина

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

## ТРЕТИЙ КЛАСС

УЧЕБНИК ДЛЯ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ
НАЧАЛЬНОГО ОБЩЕГО ОБРАЗОВАНИЯ
(НА РУССКОМ И ТАТАРСКОМ ЯЗЫКАХ)

НА ОСНОВЕ КОНЦЕПЦИИ КОММУНИКАТИВНОЙ ТЕХНОЛОГИИ
Е.И.ПАССОВА

В двух частях

ЧАСТЬ 2

КАЗАНЬ
ИЗДАТЕЛЬСТВО «ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ»
2021

УДК 811.512.145(075)
ББК 81.632.3-2я722
Х85

**Условные обозначения:**

 — начало урока

— запомни

— вспомни

 — обрати внимание

**Хайдарова, Р.З. и др.**

Х85 Татарский язык: учебник для образовательных организаций начального общего образования, в 2-х частях (на русском и татарском языках). / Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина. — Казань : Татармультфильм, 2021. — 112 с. : ил. — (Татар теле). — ISBN 978-5-9903561-5-3.

**ISBN 978-5-9903561-5-3**

**УДК 811.512.145(075)**
**ББК 81.632.3-2я722**

© Издательство «Татармультфильм», 2021
© Художественное оформление
Издательство «Татармультфильм», 2021
Все права защищены






ИЗДАТЕЛЬСТВО
«Татармультфильм»

# ТУГАН ЯККА КЫШ КИЛДЕ



## 88–90 нчы дәресләр

**1.** Сүзләрне дөрес укы.

Чыршы [чыршы́], таныш [та°ны́ш], җыр [җы́р], яңа ел [йа°ңа́ йы́л], Кыш бабай [кы́ш ба°ба́й], бәйрәм [бәйрә́м].

**2.** Шигырьне укы. Ошаса, ятла.



**Яше́л чыршы́**

Тышта́ бура́н бөте́н җиргә́  
Карла́р тутыра́.  
Безне́ң бүлмәдә́ я́мь-яшел  
Чыршы́ утыра́.

Җәва́д Тәрҗема́н

**3.** Дөрес тәрҗемәне тап.

| | | |
|---|---|---|
| чыршы́ | | зима |
| кыш | ? | дружный |
| дус | | песня |
| җыр | | ёлка |

**4.** Найди в тексте стихотворения слова, отвечающие на вопрос **ни́нди?**

**5.** Ноктала́р урынына сүзләр куй.

1) Таны́ш **(кем?)** ... . 2) **(Ни́нди?)** ... чыршы́. 3) **(Ни́нди?)** ... ел.

**6.** Ты согласен с данными утверждениями?

– Яңа́ ел бәйрәмé кө́з көне була́.
– Яңа́ ел бәйрәмé кы́ш көне була́.
– Яңа́ елда́ чыршы́ бизи́ләр.
– Яңа́ елда́ уйны́йлар, җырлы́йлар, бии́ләр.

**7. Исеңдә калдыр!**

**бәйрә́м** – праздник
**Яңа́ ел бәйрәмé** – праздник Нового года
**Яңа́ ел бәйрәме+нә́** – на праздник Нового года
**Яңа́ ел бәйрәме+ндә́** – на празднике Нового года

**8.** Нинди бәйрәмнәр бар?









**9.** Диалогны дусларың белән сөйләш.

– Гөлна́з, син бәйрәмгә́ бара́сыңмы?
– Ни́нди бәйрәмгә́?
– Яңа́ ел бәйрәменә́.
– Яңа́ ел бәйрәме́ ка́йда була́?
– Мәктәптә́.

**10.** Дополни диалог, разыграй его с другом.

– О́ля, ә́йдә Яңа́ ел бәйрәменә́ бара́быз.
– Яры́й. Сәга́ть ни́чәдә?
– Сәга́ть өчтә́.
– Син бәйрәмдә́ ни́шлисең?
– ... .

**11.** Научись писать поздравление с Новым годом.




**12.** Напиши поздравление своему учителю.

## 91–92 нче дәресләр

**1.** Тәрҗемә ит.

Начинается учебный год. – ... .
Начинается праздник. – ... .
Начинается новый год. – ... .
Начинаются каникулы. – ... .

**2.** Бәйрәм сәгать ничәдә башлана?



**3.** Прочитай и скажи, какие слова отвечают на вопрос **ни́чәнче?**, а какие – на вопрос **ни́чә?**

Бер, беренче́, ике́, икенче́, өч, өченче́, дүрт, дүртенче́, биш, бишенче́.

**4.** Дөрес тәрҗемәне тап:

**приготовили концерт** – ...
1) хәзер концерт була;
2) концерт әзер;
3) концерт әзерләдек.

**5.** Переведи по образцу.

О б р а з е ц: одевается зайчиком – куян булып киенә

одевается волком – ...
одевается медведем – ...
одевается снежинкой – ...
одевается Снегурочкой – ...
одевается волшебником – ...



**6.** Текстны укы. Ә син чыршы бәйрәмендә нишлисең?



### Чыршы́ бәйрәме́

Бүге́н мәктәптә́ чыршы́ бәйрәме́ була́. Бәйрә́м көндезге́ сәга́ть икедә́ башлана́. Безне́ң белән икенче́, өченче́ сыйныф укучылары́ була́лар.

Без бәйрәмгә́ конце́рт әзерләде́к. Мин шигы́рь сөйли́м. Мара́т, Оле́г, Ната́ша җырлы́йлар. Ләлә́ белән Ва́ля бийләр. Энҗе́ Ка́р кызы була́. Аза́т һәм Пе́тя куя́н булы́п киенә́ләр, ә Серге́й, Илну́р аю́ булы́п киенә́ләр.

**7.** Җөмләләрне дәвам ит (продолжи).

1) Без бәйрәмгә́ конце́рт ... . 2) Бәйрә́м көндезге́ сәга́ть икедә́ ... . 3) Мин шигы́рь ... . 4) Ләлә́ белән Ва́ля ... . 5) Мара́т, Оле́г, Ната́ша ... .

**8.** Сүзләр белән җөмләләр төзе. Дәфтәреңә яз.

Кы́ш бабай, чыршы́ бәйрәме́, Ка́р кызы, биеде́к, җырлады́к.

**9.** Рәсемнәр урынына – сүзләр, нокталар урынына кушымчалар куй. Дәфтәреңә яз.

Бүге́н  бәйрәме́ бул... . Мин  булы́п киен... . Аза́т, Ками́л  булы́п киен... , ә Рами́л, Оле́г  булы́п киен... .

**10.** Дополни диалоги. Поговори с соседом по парте.

1) – Рөстә́м, син нә́рсә булы́п киенә́сең?
   – ... . Ә син?
   – ... .
2) – Бәйрәмдә́ син ни́шлисең?
   – ... . Ә син?
   – ... .

**11.** Найди отличия в картинках.

О́ля  Алсу́

**12.** «Чыршы бәйрәме» текстын сөйләргә өйрән.

## 93–94 нче дәресләр

**1.** Шигырьне укы. Ошаса, ятла.

**Салкы́н, саф һава́**

Салкы́н, саф һава́,
Йомша́к кар ява́,
Урамга́ чыкса́ң,
Битлә́р кызара́.

Кар бөртекләре́
Өстеңә́ куна́,
Үзләре́ мату́р
Һәм салкы́н була́.

Әминә́ Бикчәнтә́ева



**2.** Бу сүзләрне дөрес укыйсыңмы?

Кыш [қы̆ш], салкын [салқы̆́н], кыска [қы̆сқа́], кар [қаºр], ап-ак [а́ºп̄ақ], йомшак [йŏмша́қ], кыр [қы̆р], болын [бŏлŏ́н].

**3.** К какому времени года относятся эти месяцы? Напиши в тетрадь по образцу.

Ү р н ә к: Декабрь, гыйнвар, февраль – кыш айлары.

Июнь, июль, август – ... .

Март, апрель, май – ... .

Сентябрь, октябрь, ноябрь – ... .

**4. Исеңдә калдыр!**



**Сыйфа́т** – имя прилагательное
Имена прилагательные обозначают признаки предметов и отвечают на вопрос **ни́нди?** (какой? какая? какое?).

**салкы́н** кыш (холодная зима)
**ак** кар (белый снег)
**кыска́** көн (короткий день)

**5.** Подбери к существительным подходящие прилагательные и запиши в тетрадь.

Тау, көн, кар, җил, елга́, урма́н, шәһә́р, бәйрә́м.

**6.** Бу билгеләр кайсы ел фасылына туры килә? Таблицаны тутыр, дәфтәреңә яз.

| Кыш | Көз |
| --- | --- |
| ... | ... |

Салкы́н, салкы́н яңгы́р ява́, яфракла́р коела́, кар ява́, җир а́п-ак, тышта́ бура́н, көннә́р кыска́, төннә́р озы́н, көчле́ җил исә́, кошла́р җылы́ якка́ китә́ләр.

**7.** Кыш һәм көз турында бер-берегезгә сораулар бирегез.

**8.** Җөмләләрне язып бетер.

1) Салкы́н кыш ... . 2) А́п-ак кар ... .
3) Салкы́н җил ... . 4) Кы́ш көне төннә́р ... .

**9.** Сүзләрнең антоним парларын тап, дәфтәреңә яз.

| | ? | |
| --- | --- | --- |
| салкы́н | | ка́п-кара |
| а́п-ак | | төн |
| кыска́ | | җылы́ |
| көн | | озы́н |

**10.** Прочитай текст. Подбери вопросы к выделенным словам.

кайчан? нинди? кайда? ничәнче?

Көннә́р **салкы́н. Беренче́** кар яуды́. **Елгада́** боз туңды́. Безгә́ рәхә́т. **Мәктәптә́н соң** урамга́ чыга́быз.

**11.** Дополни диалоги. Разыграй их с соседом по парте.

а) – Ко́ля, тышта́ (на улице) бура́нмы?
– Бура́н юк, лә́кин кар ява́.
– ... ?
– Салкы́н тү́гел.

ә) – ... ?
– Әйе́, бүге́н кар яуды́.
– ... ?
– Әйе́, урамга́ чыга́м.

б) – Аза́т, ә́йдә урамга́ чыга́быз.
– ... .
– Ни́ өчен?
– ... .

## 95–97 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**



Эти слова помогут тебе рассказать о погоде:
**һава́ торышы́** – прогноз погоды,
**ая́з** – ясная погода,
**болытлы́** – облачно,
**көчле́ җил исә́** – дует сильный ветер.

**2.** Отгадай загадку.

Кышы́н тауда́н шуа́быз,
Җәе́н алы́п куя́быз.





**3.** Прочитай сообщение диктора. Перескажи другу.




Һава́ торышы́н ты́ңлагыз. Бүге́н көн салкы́н, көчле́ җил исә́. Температу́ра: төнлә́ 17, көнде́з 10 гра́дус салкы́н.

**4.** Термометрларга кара һәм әйт: көн нинди?



**5.** Дополни диалоги. Поговори с соседом по парте.

а) – Бүге́н көн ни́нди?
– … .
– Ни́чә гра́дус салкы́н?
– … .



ә) – Бүге́н көн ни́нди?
– … .
– Ә температу́ра ни́нди?
– … .



**6.** Диалогны тәрҗемә ит. Дустың белән сөйләш.

а) – Какая сегодня погода?
– Холодно. Дует ветер. Снег идёт.
– Температура какая?
– Минус 15 градусов.

ә) – Коля, выходи на улицу.
– Я не выйду.
– Почему?
– Потому что очень холодно.

**7.** Допустим, ты диктор и объявляешь прогноз погоды.

Как скажешь, что на улице:
– тепло, ветра нет, температура $+5^{\circ}$ C;
– холодно, вьюга, температура $-20^{\circ}$ C?

**8.** **Исеңдә калдыр!**

**һәрвакыт** – всегда **анна́н соң** – потом

**9.** Рәсемнәр урынына тиешле сүзләрне куй. Текстны сөйләргә өйрән.

Ди́ма, Аза́т, Әми́р – дусла́р. Ала́р һәрвакыт бергә́ уйны́йлар.

Бүге́н көн җылы́, җил юк,  ява́. Ди́ма  ала́, Аза́т белән Әми́р  ала́лар. Малайла́р би́к оза́к  шуа́лар. Анна́н соң бергә́ дәре́с әзерли́ләр.

**10.** Выпиши из текста глаголы, поставь их в прошедшем времени. Расскажи содержание изменённого текста.

**11.** Составь диалог по тексту.

**12.** Узнай у друга:

– какая сегодня погода;
– какая температура воздуха;
– есть ли у него лыжи;
– катается ли он на лыжах.

**13.** Предложи другу:

– играть вместе на улице;
– кататься вместе на лыжах;
– играть в хоккей;
– кататься на коньках.

## 98–100 нче дәресләр

**1.** Таблицаны тутыр.

| | тау | шугалак | бәйрәм |
|---|---|---|---|
| Кая? | ... | ... | ... |
| Кайда? | ... | ... | ... |
| Кайдан? | ... | ... | ... |

**2.** Составь предложения со словами из упражнения №1. Используй глаголы **бара́, уйны́й, шуа́, кайта́, китә́.**

**3.** Сүзләрнең антоним парларын тап.

| | | |
|---|---|---|
| бар | | аз |
| килде́ | ? | салкы́н |
| күп | | юк |
| жылы́ | | китте́ |

**4.** Фигыльләрне үрнәк буенча үзгәрт (измени по образцу), тәрҗемә ит, җөмләләр төзе.

Ү р н ә к: кил – приходи; килә́ – приходит; килде́ – пришёл.

Ф и г ы л ь л ә р: шу, кит, бир.

**5.** Рәсемнәр урынына – сүзләр, ноктлар урынына кушымчалар куй. Текстны укы.

### Тауда

Мине́м  юк. Лә́кин мин тау... китте́м. Тау... балала́р күп иде. На́йл, Аза́т  шуа́лар, ә Ко́ля, Са́ша  шуа́лар. Мин На́йл һәм Аза́т янына́ килде́м. Ни́чек рәхә́т, күңелле́ тауда́! Мине́м  юк шул!



Мине́м янга́ На́йл килде́ дә:

– Мә, Ко́стя, си́н дә шу, – диде́.

Ул миңа́ чаңгы́ бирде́. Миңа́ би́к рәхә́т булды́! Рәхмә́т синә́, дусты́м!

**6.** Ике раслауның кайсысы дөрес?

1) Мине́м чаңгы́м бар.
   Мине́м чаңгы́м юк.
2) Азатны́ң чаңгысы́ бар.
   Азатны́ң чаңгысы́ юк.
3) Наи́л, Аза́т чаңгы́ шуа́лар.
   Наи́л, Аза́т чана́ шуа́лар.
4) Наи́л Ко́стяга чана́ бирде́.
   Наи́л Ко́стяга чаңгы́ бирде́.

**7.** Җөмләләрне дәвам ит.

Мин таугá … . Таудá балалáр … . Балаларгá таудá … . Миңá Наи́л чаңгы́ … . Миңá би́к … булды́.

**8.** Сорауларга җавап бир.

1) Ко́стяның чаңгысы́ бáрмы?
2) Таудá ке́мнәр бáр иде?
3) Наи́л Ко́стяга нәрсә бирде́?

**9.** **Исеңдә калдыр!**

**юмáрт** – щедрый **сарáн** – жадный

**10.** Бу бәяләрнең кайсысы Наилгә туры килә?

Яхшы́, начáр, юмáрт, сарáн, әйбә́т, тәрбияле́.

**11.** Хикәядә **мин** сүзен **Костя** һәм **ул** сүзләре белән алыштыр (замени). Хикәядәге җөмләләр ничек үзгәрер (изменятся)? Хикәяне яз.

**12.** Иң яхшы хикәя сөйләүчегә конкурс! Бәя бирергә онытма!

| | |
|---|---|
| Сәнгатьле́ сөйли́.<br>Сүзләрне́ дөре́с әйтә́.<br>Хата́ яса́мый.<br>Яхшы́ сөйли́. | Сәнгатьле́ сөйлә́ми.<br>Сүзләрне́ дөре́с ә́йтми.<br>Хата́ ясы́й.<br>Яхшы́ сөйлә́ми. |

**13.** Рәсемнәр урынына сүзләр куй, диалогны укы. Дустың белән сөйләш.

а) – Та́ня, ә́йдә урамгá чыгáбыз.

– Ә́йдә. Ә  барáбызмы?

– Ә́йдә бүге́н шугалаккá барáбыз! Сине́ң  бáрмы?

– Бар. Әние́м миңá яңá  бүлә́к итте́.

ә) – Илну́р, ә́йдә таугá барáбыз,  шуáбыз.

– Мине́м  юк, Сәли́м,  гына бар.

– Яры́й, Илну́р. Мин чанамны́ алá́м, ә син чаңгыңны́ ал. Мин сине́ тáу янындá көтә́м.

б) – Марáт, бүге́н хокке́й уйнаргá чык!

– Сәгáть ни́чәдә?

– 

**14.** Спроси у друга:

– есть ли у него санки, лыжи, коньки;
– играет ли он зимой на улице;
– катается ли он на санках, лыжах, коньках.

## 101–103 нче дәресләр

**1.** Подумай и скажи, к каким (зимним или летним) видам спорта относятся эти предметы.



**2. Исеңдә калдыр!**



**яры́ш** – соревнование
**чаңгы́ ярышы́** – лыжные соревнования

**3.** Сорауларга җавап бир, җөмләләрне дәвам ит.

**Нә́рсә бара́?**
Чаңгы́ ярышы́ бара́.
Волейбо́л … … .
…

**Ка́я бара́сың?**
Чаңгы́ ярышына́ бара́м.
Волейбо́л … … .
…

**4.** Дополни диалоги. Поговори с соседом по парте.

а) – Ко́ля, син чаңгы́ ярышына́ бара́сыңмы?
– … .
– Ә чаңгы́ ярышы́ ка́йда була́?
– … .

ә) – Айгө́л, син чаңгы́ ярышына́ барды́ңмы?
– Әйе́, барды́м.
– … ?
– Беренче́ уры́н алды́м.
– … !

**5.** Хикәяне укы. Син Федяга нинди киңәш бирер идең?




### Дусла́р

Иго́рь белән Фе́дя – дусла́р. Җә́й көне бергә́ футбо́л уйны́йлар, кы́ш көне чаңгы́ шуа́лар. Ала́р икесе́ дә би́к яхшы́ шуа́лар.

Ме́нә бүге́н чаңгы́ ярышы́ була́. Малайла́р бергә́ чаңгы́ ярышына́ киттелә́р. Тиздә́н фи́ниш. Ала́р бергә́ киләләр иде. Ки́нәт Иго́рь егылды́. Аны́ң чаңгысы́ сынды́, аягы́ авыртты́. Ә фи́ниш би́к якы́н. Фе́дяга ни́шләргә?

**тиздә́н** – скоро
**якы́н** – близко
**ки́нәт** – вдруг
**сынды́** – сломалась
**егылды́** – упал

**6.** Син бу сүзләрне дөрес укыдыңмы?

Кыш көне [қы́ш көнө], чаңгы [чаңғы́], шуалар [шуа́лар], ярыш [йа°ры́ш], яхшы [йа°хшы́], сынды [сы́нды], авыртты [а°wы́рт̄ы́].

**7.** Нокталар урынына нинди хәрефләр куярсың?

| | | |
|---|---|---|
| ...хшы | ...рыш | й...зә |
| ...кын | ...гылды | й...герә |

**8.** Хикәядән фигыльләрне тап. Таблицага яз.

| Действие происходит сейчас | Действие уже произошло |
|---|---|
| уйныйлар | уйнадылар |
| ... | ... |

**9.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп укы.

Җәй ... бергә́ ... уйны́йлар, кыш ... ... шуа́лар. Ала́р икесе́ дә бик ... шуа́лар. Бүге́н ала́р ... чаңгы́ ... киттелә́р. Ки́нәт И́горь ... . Фи́ниш би́к ... .

**10.** Сорауларга җавапны хикәядән тап.

1) И́горь белән Фе́дя бергә́ ни́шлиләр? 2) Ала́р чаңгыда́ ни́чек шуа́лар? 3) Чаңгы́ ярышында́ нә́рсә булды́?

**11.** Хикәянең эчтәлеген (содержание) бер-берегезгә (друг другу) сөйләгез.

## 104–105 нче дәресләр

**1.** Бу җөмләләрнең эчтәлеге «Дуслар» хикәясенә туры киләме (подходит)?

1) И́горь белән Фе́дя җә́й көне бергә́ футбо́л уйны́йлар, кы́ш көне чаңгы́ шуа́лар.

2) И́горь белән Фе́дя бүге́н волейбо́л ярышына́ киттелә́р.

3) Чаңгы́ ярышында́ И́горь егылды́.

4) И́горьның чаңгысы́ сынды́, аягы́ авыртты́. Фи́нишка ера́к әле.

2. Җөмләләрне хикәя эчтәлеге тәртибендә урнаштыр.

1) Ала́р бергә́ чаңгы́ ярышына́ киттелә́р. 2) И́горь белән Фе́дя – дусла́р. 3) Тиздә́н фи́ниш. 4) Аны́ң чаңгысы́ сынды́, аягы́ авыртты́. 5) Кинә́т И́горь егылды́.

3. «Дуслар» хикәясен иң яхшы сөйләүчегә конкурс!

4. Как скажешь, что:

– завтра будут лыжные соревнования;
– Коля ушёл на лыжные соревнования?

5. Спроси у друга:

– любит ли он кататься на санках;
– играет ли он зимой на улице;
– с кем он больше любит играть.

6. Бу диалоглар кайсы рәсемгә туры килә?



а) – И́горь, тизрә́к! Фи́ниш якы́н!
– Фе́дя, мин егылды́м. Аягы́м авырта́.
– Хә́зер мин сиңа́ булыша́м.



ә) – И́горь, тизрә́к! Фи́ниш якы́н!
– Фе́дя, мин егылды́м. Аягы́м авырта́.
– Үзе́ң тор! Мин фи́нишка китте́м.

7. Җөмләләрне дәвам ит.

1) Фе́дя ярдә́м и́тмәде, чө́нки ... .
2) Фе́дя ярдә́м итте́, чө́нки ... .
3) Фе́дя ярдә́м итте́, шуңа́ күрә ... .

8. Как ты продолжишь этот рассказ? Напиши.

9. Расскажите друг другу написанный вами рассказ.

## 106–108 нче дәресләр

1. Сүзләрне дөрес укы.

Чана [ча°на́], якын [йакы́н], бабасы [ба°басы́] гыйнвар [ғы́йнwа́р], җитте [җит̄э́], авыл [а°wы́л], әбәкле [әбәклэ́], көттеләр [көт̄ѳлә́р], шаярдылар [ша°йардылa̍р].

2. Вместо точек вставь слова **әби, бабай, чана.** Подчеркни окончания.

Миним ... .    Синең ... .    Аның ... .

3. Хикәяне укы.

### Кани́кулда



Гыйнва́р ае́ җитте́. Кани́кул башланды́. Айра́т кани́кулда авылга́ китте́. Авылда́ аны́ң әбисе́, бабасы́ бар. Әбисе́ дә, бабасы́ да Айратны́ көттелә́р. Ала́р малайга́ чана́ бүлә́к иттелә́р. Айра́т аларга́ рәхмә́т әйтте́. Ул би́к шатланды́. Хә́зер аны́ң яңа́ чанасы́ бар! Айра́т дусты́ Ю́ра белән чана́ шуды́.

Малайла́р авылда́ әбәкле́ уйнадыла́р, шаярдыла́р, көлделә́р. Авылда́ би́к күңелле́, рәхә́т булды́.

**әбәкле́ уйнадыла́р** – играли в пятнашки

**4.** Поставь вопросы к выделенным словам. Составь вопросительные предложения.

1) Айра́т **кани́кулда** авылга́ китте́. 2) Әбисе́ дә, бабасы́ да **Айратны́** көттелә́р. 3) Ала́р **малайга́** чана́ бүлә́к иттелә́р. 4) Айра́т дусты́ **Ю́ра белән** чана́ шуды́. 5) **Авылда́** би́к күңелле́, рәхә́т булды́.

**5.** Расположи предложения по содержанию текста.

1) Әбисе́ дә, бабасы́ да Айратны́ көттелә́р. 2) Айра́т кани́кулда авылга́ китте́. 3) Малайла́р авылда́ әбәкле́ уйнадыла́р. 4) Ала́р малайга́ чана́ бүлә́к иттелә́р. 5) Авылда́ би́к күңелле́, рәхә́т булды́. 6) Айра́т аларга́ рәхмә́т әйтте́.

**6.** Айрат авылда нишләде? Дустыңа сөйлә.

Кани́кулда Айра́т  кит... .

Авыл... аны́ң   яши́. Ала́р малайга́ 

бүлә́к ит... . Айра́т дусты́ Ю́ра белән 

шу... . Малайла́р  уйна... , шаяр... ,

көл... .

**7.** Измени данные слова, отвечая на вопрос Шурале.



**Нишләмәде?**

| | | |
|---|---|---|
| китте́ – ... | бүлә́к итте́ – ... | рәхмә́т әйтте́ – ... |
| шатланды́ – ... | шуды́ – ... | уйнады́ – ... |

**8.** Спроси у друга:

– есть ли у него коньки (лыжи, санки);
– нужны ли ему коньки (лыжи, санки);
– катается ли он с горки;
– идёт ли он на каток;
– куда он ездил на каникулы.

**9.** Какие из этих диалогов подходят к содержанию рассказа «Каникулда»? Разыграйте диалоги.

1) – Исә́нме, әбие́м! Исә́нме, баба́м!
– Исә́нме, улы́м! Без сине́ көтте́к, – диделә́р әбисе́ һәм бабасы́.

2) – Ю́ра, мине́м яңа́ чана́м бар. Әбие́м белән баба́м бүлә́к иттелә́р.
– Безне́ң өй янында́ та́у бар. Ә́йдә шуа́быз.

3) – Фе́дя, ә́йдә урамга́ чыга́быз. Әбәкле́ уйны́йбыз.
– Хә́зер чыга́м.

**10.** Прочитай диалог, вставляя пропущенные предложения. Разыграй его с соседом по парте.



– Илну́р, син кани́кулда ка́я барды́ң?
– ... .
– Ә мин өйдә́ булды́м. Китаплә́р укыды́м, мультфи́льмнар карады́м. Ә син китапла́р укыды́ңмы?
– ... .

**11.** Җөмләләрне тәгәллә (закончи). Дәфтәреңә яз.

1) Без укы́мыйбыз, чө́нки ... .
2) Мине́м яңа́ чана́м бар, шуңа́ күрә ... .
3) Без кани́кулны ярата́быз, чө́нки ... .
4) Мин авыры́йм, шуңа́ күрә ... .

**12.** «Каникулда» хикәясен сөйлә.

## 109–110 нчы дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Кыш билгеләре турында сөйлә.

**2.** Сүзләрнең антонимнарын яз.

| | |
|---|---|
| салкы́н – ... | бара́ – ... |
| озы́н – ... | а́п-ак – ... |
| аз – ... | төн – ... |
| көн – ... | күп – ... |

**3.** Подготовь сообщение о погоде.

**4.** Нокталар урынына кушымчалар куй. Җөмләләрне укы.

1) Нәси́м авыл... китте́.
2) Нәси́м авыл... яши́.
3) Нәси́м авыл... шәһәргә́ кайтты́.



**5.** Переведи по образцу.

1) Образец: Наступил январь. – Гыйнвар житте.

Наступил февраль. – ... .
Наступил март. – ... .

2) Образец: его мать – аның әнисе; әнисе

его дедушка – ...
его отец – ...
его брат – ...
его лыжи – ...
его санки – ...

**6.** Измени данные слова по образцу. Поставь к ним вопросы.

| | | | |
|---|---|---|---|
| кит | китә | китте | китмәде |
| көт | ... | ... | ... |
| бүләк ит | ... | ... | ... |
| шатлан | ... | ... | ... |
| шу | ... | ... | ... |
| уйна | ... | ... | ... |
| бар | ... | ... | ... |

**7.** Спроси у друга:

– есть ли у него санки (лыжи);
– идёт ли он на каток (горку);
– идёт ли он на праздник;
– идёт ли он на лыжные соревнования.

**8.** Позови друга:

– вместе играть на улице;
– кататься на лыжах;
– кататься на санках;
– играть в хоккей;
– вместе пойти на праздник.



**9.** Как скажешь другу о том, что:

– ты идёшь на новогодний праздник;
– праздник начинается в 16 часов;
– ты написал открытку маме (папе, бабушке, дедушке, учительнице, другу)?

**10.** Напиши поздравительную открытку на Новый год маме (папе, бабушке, дедушке, учителю).

**11.** Сезнең мәктәптә Яңа ел бәйрәме ничек үтә? Хикәя төзе һәм дәфтәреңә яз.



# ШӘҺӘРДӘ ҺӘМ АВЫЛДА

## 111–112 нче дәресләр




**1.** Төрләнешне өйрән.

| | |
|---|---|
| Мин яши́**м** (тора́**м**). | Без яши́**без** (тора́**быз**). |
| Син яши́**сең** (тора́**сың**). | Сез яши́**сез** (тора́**сыз**). |
| Ул яши́ (тора́). | Ала́р яши́**ләр** (тора́**лар**). |

**2.** Антоним парларны билгелә.

| | | |
|---|---|---|
| әкре́н | ? | зур |
| кечкенә́ | | җите́з |
| күп | | ямьсе́з |
| мату́р | | аз |

**3.** Текстны укы. Исем бир.

Без Татарстанда́ яши́без. Татарста́н – зур, бай респу́блика. Татарстанда́ зур шәһәрлә́р, мату́р авылла́р, яше́л урманна́р, елгала́р һәм күллә́р би́к күп. Урманнарда́ хәйләкә́р төлкелә́р, җите́з куянна́р, уса́л бүрелә́р, көчле́ пошила́р яши́.

**4.** Выпиши из текста сначала слова, отвечающие на вопрос **нәрсә?**, а потом – на вопрос **нинди?**

**5.** Дополни диалог. Разыграй его с соседом по парте.

– … ?
– Мин Татарстандá яши́м.
– … ?
– Татарстáн – зур, бай респу́блика.

**6.** Расскажите содержание упражнения №3 друг другу.

**7.** **Исеңдә калдыр!**



| | |
|---|---|
| **тел** – язык | **ру́сча** – по-русски |
| **миллә́т** – нация | **татáрча** – по-татарски |

**татáр телé** – татарский язык

**8.** Милләт исемнәрен татарча әйт.



Русские – руслар; татары – …; башкиры – …; евреи – …; марийцы – …; украинцы – …; чуваши – …; узбеки – …; удмурты – …; таджики – … .

**9.** Дополни диалоги. Поговори с соседом по парте.

а) – Ко́ля, син ни́нди телдә́ сөйләшә́сең?
– ... . Ә син, Айну́р?
– ... .

ә) – Ко́ля, син тата́рча яхшы́ белә́сеңме?
– ... .
– ... ?
– Миңа́ тата́р теле́ ошы́й.

**10.** Спроси у друга:

– знает ли он татарский язык;
– разговаривает ли он на татарском языке;
– с кем он разговаривает на татарском языке.

**11.** Выполни письменно упражнение №10.

## 113–115 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**



**шәһә́р** – город **Каза́н шәһәре́** – город Казань
**ура́м** – улица **Ба́уман урамы́** – улица Баумана

**2.** Дәвам ит.

Үрнәк: Бу ни́нди шәһә́р? – Бу – Әлмә́т шәһәре́.

Каза́н, Чиста́й, Мәскә́ү, Яр Чаллы́, Алабуга́, Сама́ра, Түбән Ка́ма, Санкт-Петербу́рг, Түбән Но́вгород.

**3. Исеңдә калдыр!**



– Бу ни́нди ура́м?
– Бу – Ба́уман урамы́.
– Син ка́йсы урамда́ яши́сең?
– Мин Ба́уман урамында́ яши́м.

**4.** Үрнәк буенча дәвам ит.

Үрнәк: Син ка́йсы урамда́ яши́сең? – Мин Мәскә́ү урамында́ яши́м.

Урам исемнәре: Сөембикә́, Чулма́н, Тука́й, Тынычлы́к, Кол Гали́, Пу́шкин.

**5.** Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куй, дәфтәреңә яз.

1) Әлмә́т шәһәр... би́к мату́р. 2) Ко́стя ни́нди шәһәр... яши́? 3) Ко́стя Чистай... яши́. 4) Алсу́, син ни́нди шәһәр... яши...? 5) Кита́п кибете́ Ба́уман урамы... урнашка́н.

**6.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: кем нәрсәдә бара?

Аза́т  ... . Ди́ма  ... . Алсу́  ... .

**7.** Нокталар урынына **тора, уйный** сүзләрен куеп укы.

Мин бара́м, ... , ... .
Син бара́сың, ... , ... .
Ул бара́, ... , ... .

Без бара́быз, ... , ... .
Сез бара́сыз, ... , ... .
Ала́р бара́лар, ... , ... .

**8.** Нокталар урынына кушымчалар өстә. Дәфтәреңә яз.

Мин / Арча... яшим.
Мин – Арча... килдем.
Мин \ Арча... барам.

Мин / Казанга поезд... барам.
Мин – Арчага машина... барам.
Мин \ Әлмәткә автобус... барам.

**9. Исеңдә калдыр!**

| | |
|---|---|
| **йорт** – дом | **йокы́ бүлмәсе́** – спальня |
| **бүлмә́** – комната | **аш бүлмәсе́** – кухня |
| **фати́р** – квартира | **куна́к бүлмәсе́** – зал |
| **кат** – этаж | |

**10.** Кем ничәнче катта яши?



 – Аза́т  – Дами́р  – Ма́ша  – Алсу́

 – Ка́тя  – Айгө́л  – Оле́г

**11.** Помоги Гали перевести вопросы.

**нәрсә?**

**ничә? ничәнче?**

**ничек? нинди?**

**кайсы? кайда?**



**12.** Диалогларга төшеп калган репликаларны өстә. Дустың белән сөйләш.

а) – Син ка́йсы урамда́ яши́сең?
– ... .
– Ни́чәнче йортта́ тора́сың?
– ... .
– Ни́чәнче фатирда́ тора́сың?
– ... .

ә) – ... ?
– Мин бишенче́ мәктәптә́ укы́йм.
– Мәктәпкә́ ни́чек бара́сың?
– ... .

**13.** Сорауларга җавап яз.

1) Син ка́йсы шәһәрдә́ яши́сең?
2) Син ни́нди урамда́ тора́сың?
3) Син ни́нди йортта́, ни́чәнче катта́, ни́чәнче фатирда́ тора́сың?
4) Ни́чәнче мәктәптә́ укы́йсың?
5) Мәктәпкә́ ни́чек бара́сың?

## 116–117 нче дәресләр

**1.** Бу сүзләрне дөрес укы.

Урамнар [ура°мна́р], озын [ŏзŏ́н], биек [бийә́к], йорт [йŏрт], катлы [ҡа°тлы́], кибет [кибә̆́т], ашамлыклар [а°шамлы́ҡла́р], еш [йыш].

2. Сүзләрнең антоним парларын тап.

| | | |
|---|---|---|
| киң | ? | кечкенә́ |
| зур | | тар |
| озы́н | | күп |
| аз | | кыска́ |

3. Текстны укы, исем бир.



Мине́м исеме́м Ди́ма. Мин шәһәрдә́ яши́м. Безне́ң шәһәр би́к зур. Урамна́р киң һәм озы́н.

Йортла́р да бие́к. Безне́ң шәһәрдә́ 5 катлы́, 9 катлы́ йортла́р күп, ә 12, 16 катлы́ йортла́р азра́к.

Шәһәрдә́ авто́буслар, тролле́йбуслар, трамвайла́р, таксила́р йөри́.

Мин мәктәпкә́ авто́буста бара́м. Әни́ эшкә́ трамва́й белән йөри́. Мин Шами́л Усма́нов урамында́, җиденче́ йортта́ яши́м.

Безне́ң өй янында́ зур кибетлә́р бар: киемнә́р кибете́, ашамлыкла́р кибете́, «Балала́р дөньясы́» кибете́.

Шәһәрдә́ музейла́р, теа́трлар бар. Мин дусла́р белән ци́ркка, теа́трга бара́м.

Мин безне́ң шәһәрне́ ярата́м, чө́нки ул зур, чиста́ һәм мату́р.

**азра́к** – меньше
**трамва́й белән** – на трамвае
**балала́р дөньясы́** – детский мир

**4.** Сорауларга җавапны тексттан тап һәм укы.

1) Ди́ма ка́йда яши́?
2) Шәһәрдә́ ни́чә катлы́ йортлá́р бар?
3) Шәһәрдә́ ни́нди тра́нспортлар йөри́?
4) Ди́ма мәктәпкә́ нә́рсә белән йөри́?

**5. Исеңдә калдыр!**

**Мин Казангá автóбуста барáм.** – Я еду в Казань на автобусе. **Мин Мәскәүгә поездда барам.** – Я еду в Москву на поезде.

**6.** Җөмләләрне киңәйтеп яз. Һәр яңа җөмләгә сорау куй.

Ү р н ә к: Мин барáм.
Мин мәктәпкә́ барáм.
Мин мәктәпкә́ автóбуста барáм.
Җ ө м л ә л ә р: Мин яши́м. Мин яратáм.

**7.** Рәсемнәр урынына сүзләр куй.

1) Мин мәктәпкә́  барáм, ә әни́  барá.

2) Безнé́ң  янындá 

бар.

3) Шәһәрдә́ 

, 

, 

бар.

**8. Исеңә төшер!**

**шуңá күрә** – поэтому

**9.** Җөмләләрне дәвам ит.

1) Теáтр якы́н тҮгел, ... автóбуста барáм. 2) Мин дүртенче́ каттá торáм, ... ли́фтта менә́м. 3) Йорт янындá кибетлә́р бар, ... машиналáр күп.

**10.** Үзең яшәгән шәһәр (авыл) турында хикәя яз.

## 118–119 нчы дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**

Чтобы показать, что предмет обладает каким-нибудь качеством в большей или меньшей степени, чем другой, говорим так:

**зур** – зур**рáк** (больше),
**матýр** – матур**рáк** (красивее),
**кечкенә́** – кечкенә**рә́к** (меньше).

Это сравнительная степень прилагательного – **сыйфатны́ң чагыштыры́ дәрәҗәсе́.**

**2.** Бу предметларның кайсылары зуррак?







**3.** Бу йортларның кайсысы биегрәк?

**4.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне куй.

1) Алабугá – зур шәһә́р, ә Яр Чаллы́ ... .
2) Әгерҗе́ – кечкенә́ шәһә́р, ә Минзәлә́ ... .

**5.** Нокталар урынына – кушымчалар, ә рәсемнәр урынына сүзләр куеп укы.

1) Мин шәһәр...  бара́м.

2) Мин авыл...  кайта́м.

3) Мин район...  бара́м.

4) Мин район...  кайта́м.

**6.** Напиши вопросы к предложениям упражнения №5.

**7.** Дустың белән сөйләш.



а) – Ко́ля, ә́йдә Казангá барá́быз.
– Син ке́м белән барá́сың?
– Әни́ белән.
– Кá́йчан барá́сыз?
– Шимбә́ көнне́.
– Ми́н дә энидә́н сорыйм.
– Ярый, миңá шалтырá́т (звони).

ә) – Әни́, ә́йдә Казангá барá́быз.
– Кá́йчан?
– Шимбә́ көнне́. Алмá́з да энисе́ белән барá.
– Нә́рсәдә барá́лар?
– Авто́буста.
– Ярый, барá́быз.



б) – Алло́, Алмá́з, сәлá́м!
– Сәлá́м, Ко́ля! Әние́ң белән сөйләште́ңме?
– Әйе́. Әни́ ризá. Без Казангá барá́быз.
– Сәгá́ть ни́чәдә китә́без?
– Иртә́н сәгá́ть 10 да.
– Нә́рсәдә барá́быз?
– Авто́буста.




**8.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: шәһәрдә нәрсәләр бар?








**9.** Дополни диалоги. Разыграй их с соседом по парте.

а) – ... ?
– Әйé, безнéң шәһәрдә́ музéй бар.
– ... ?
– Шәһә́р музеé.

ә) – Ләлә́, ә́йдә музейга́ бара́быз.
– Мин риза́.
– ... ?
– Сәга́ть өчтә́.

б) – Наи́л, сезнéң шәһәрдә́ цирк ба́рмы?
– Юк. Безгә́ цирк Мәскәүдә́н килә́. Ә Казанда́ ба́рмы?
– ... .

**10.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куй.

Мин Каза́н шәһ...р...ндә ...шим. Ә дусты́м Аза́т Әлм...ттә ...ши. Аны́ң әтисé – нефть... .

**11.** Составь вопросы к предложениям упражнения №10.

## 120–122 нче дәресләр

**1.** **Исеңә төшер!**

**алдында́** – перед **артында́** – за
**янында́** – у, около, возле, рядом

**2.** Рәсемгә кара һәм сорауларга җавап бир.



1) Өй алдында́ нәрсә бар?
2) Өй артында́ нәрсә бар?
3) Өй янында́ нәрсә үсә́?
4) Өй эчендә́ нәрсә бар?

**3. Исеңдә калдыр!**



**һәр** – каждый
**ба́рлык** – весь, всё
**гына/генә, кына/кенә** – только

**4.** Текстны укы.

### Безне́ң авы́л

Без авылда́ яши́без. Безне́ң авылда́ бе́р генә ура́м бар. Авылда́ ба́рлык йортла́р да би́к мату́р. Һәр йорт янында́ бакча́ бар. Анда́ алмагачла́р, чиялә́р үсә́. Йортла́р артында́ бәрәңге́ һәм яшелчә́ бакчасы́ бар. Анда́ бәрәңге́, кише́р, суга́н, чөгенде́р үсә́.

Авылда́ яңа́ мәктә́п бар. Мәктә́п алдында́ чәчәклә́р күп. Мәктә́п артында́ спорт мәйданы́ бар. Тәнәфестә́ балала́р шунда́ (там) уйны́йлар.

**5.** Кайда нәрсә бар? Җөмләләрне дәвам ит.

1) Һәр йорт янында́ ... .
2) Йортла́р артында́ ... .
3) Мәктә́п алдында́ ... .
4) Мәктә́п артында́ ... .

**6.** Ике раслауның кайсысы дөрес? Дөрес раслауны дәфтәреңә яз.

1) Безнéң авылдá икé урáм бар.
Безнéң авылдá бер урáм бар.

2) Һәр йорт янындá бакчá бар.
Һәр йорт янындá бакчá юк.

3) Бакчадá алмагачлáр, чиялǽр үсǽ.
Бакчадá алмагачлáр, чиялǽр ýсми.

**7.** Дополни диалоги. Поговори с соседом по парте.

а) – ... ?
– Йортлáр артындá бакчá бар.

ә) – ... ?
– Мәктǽп алдындá чәчәклǽр үсǽ.

б) – ... ?
– Мәктǽп артындá спорт мәйданы́ бар.

**8.** Как скажешь, что:

– около дома есть сад;
– перед школой растут цветы;
– за домом есть огород;
– за школой есть спортплощадка?

**9.** Дополни диалог. Разыграй его с другом.

– Канúкул башланды́мы әле?
– Әйé, башланды́.
– ... ?
– Мин канúкулда Санкт-Петербýргка барáм.
– Ә мин авылгá кайтáм.
– Нǽрсәдә кайтáсың?
– ... .

## 123–124 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Ты не забыл названия этих городов на татарском языке? Составь с ними предложения.

Казань, Чистополь, Заинск, Набережные Челны, Елабуга, Нижнекамск.

**2.** Таблицаны тутыр.

| Татарстан шәһәрләре | Россия шәһәрләре |
|---|---|
| ... | ... |

Шәһәр исемнәре: Казáн, Мәскәý, Уфá, Чистáй, Сарáтов, Алабугá, Самáра, Зәй, Салавáт, Түбән Кáма, Минзәлә́, Бөгелмә́, Баулы́.

**3.** Сүзләрнең антонимнарын тап. Җөмләләр төзе.

Зур – ...; киң – ...; күп – ...; озын – ... .

**4.** Как скажешь, что:

– ты в Казань едешь на автобусе;
– ты в деревню едешь на машине;
– ты живёшь в высоком доме;
– в Казани живут твои друзья?

**5.** Спроси у друга:

– в каком городе он живёт;
– на какой улице его дом;
– на каком этаже его квартира;
– на чём он едет в школу.

**6.** Расскажи о своём городе (или о своей деревне).

# ӘДӘПЛЕ БУЛЫЙК

## 125–127 нче дәресләр

**1.** Рассмотри рисунки и выбери реплики, которые говорят:

– при встрече;
– при приглашении к столу;
– при просьбе.

Исәнмесез!

Сау булыгыз!

Хәерле көн!

Гафу итегез!

Хәерле иртә!

Хәерле кич!

Рәхим итегез!

Тыныч йокы!

Рәхмәт!

Ашыгыз тәмле булсын!

Зинһар!

**2.** Прочитай диалог и скажи, какие вежливые слова забыла сказать Алсу.




– Миңа́ бер шешә́ сөт һәм ипи́ би́регез.
– Ме́нә сөт, ме́нә ипи́.

**3.** Текстны укы. Ни өчен текст «Тәмле сүзләр» дип атала?

**Тәмле́ сүзлә́р**

Безне́ң телебездә́ тәмле́ сүзлә́р би́к күп. Сез аларны́ белә́сез.

Иртә́н: «Хәерле́ иртә́!» – дип әйтәбез.

Көнде́з: «Хәерле́ кө́н!» – дип әйтәбез.

Кич: «Хәерле́ ки́ч!» – ди́без.

Кич тыны́ч йокы́ тели́без. «Тыны́ч йокы́, әние́м! Тыны́ч йокы́, әтие́м! Тыны́ч йокы́ үземә́, тыны́ч йокы́ күземә́», – ди́без.

«Салава́т күпере́» журналынна́н

**4.** К каким рисункам подходят эти диалоги.



1) – Хәерле́ кө́н, Була́т.
– Хәерле́ кө́н, Оле́г.
– Син ка́я бара́сың?
– Стадионга́.



2) – Хәерле́ иртә́, Айда́р!
– Хәерле́ иртә́, Са́ша.
– Син ка́я бара́сың?
– Мәктәпкә́.



3) – Хәерле́ ки́ч, Арту́р!
– Исә́нме, Мара́т.
– Хәлләре́ң ни́чек?
– Рәхмә́т, яхшы́.

**5.** Ты умеешь разговаривать по телефону? Какой из этих диалогов тебе нравится, какой из них ты считаешь правильным?

1) – Алло́!
– Алло́!
– Мара́т өйдә́ме?
– Ә ке́м сорый́й?
– Ди́ма. Миңа́ Мара́т кирә́к.
– Хә́зер чакыра́м.



2) – Алло́, Альби́на апа́, исә́нмесез! Бу ми́н – Ди́ма. Мара́т өйдә́ме?
– Өйдә́.
– Ча́кырыгыз әле.
– Хә́зер чакыра́м.
– Рәхмә́т.

3) – Алло́, Оле́г, ни́гә стадионга́ ки́лмәдең?
– Авырый́м.
– Ка́йчан килә́сең?
– Бе́лмим.

4) – Сәла́м, Оле́г. Хәллә́р ни́чек?
– Сәла́м, Муса́!
– Оле́г, ни́гә стадионга́ ки́лмәдең?
– Авырый́м.
– Авы́рма, без сине́ көтә́без.
– Рәхмә́т.



**6.** Туган көнгә ничек чакырасың? Син кайсы чакыруны сайлыйсың?



а) – Алло́, хәерле́ ки́ч!
– Хәерле́ ки́ч!
– О́ля, си́нме?
– Әйе́, мин.
– О́ля, якшә́мбе көнне́ мине́м туга́н көне́м. Вакыты́ң ба́рмы? Мин сине́ чакыра́м.



– Сәга́ть ни́чәдә?
– Көнде́з сәга́ть уникедә́.
– Рәхмә́т. Мин килә́м.

ә) – Алло́, Ко́стя, сәла́м!
– Сәла́м, На́йл.
– Ко́стя, якшә́мбе көнне́ туга́н көнгә́ кил. Оны́тма!
– Яры́й, На́йл, килә́м.

**7.** Туган көнгә котлауны өйрән!



Настя!
Сине туган көнең белән котлыйм.
Сиңа уңышлар телим!
Дамир

**8.** Кроссвордны чиш. Марат туган көнгә нинди чәчәкләр алып килә?











## 128–130 нчы дәресләр

**1.** Рәсемгә кара һәм әйт: кемгә ничә яшь?




Найл Óля Руслáн Кáтя

**2.** Рәсемгә кара һәм әйт: кем нинди бүләк алып килде?



**3.** Допустим, к тебе на день рождения пришли друзья. Расположи рисунки по порядку праздника.



**4.** Используя рисунки упражнения №3, составь рассказ на тему «Туган көн».

**5.** Расположи диалоги по порядку проведения дня рождения. Разыграйте сценку «День рождения».

1) – Ка́йда кул юа́быз?
– Ме́нə ва́нна, ме́нə сөлге́.
– Рəхмə́т.

2) – Наи́л, без сине́ туга́н көне́ң белəн котлы́йбыз! Сиңа́ кечкенə́ бүлə́к алы́п килде́к.
– Ни́нди мату́р бүлəклə́р, рəхмə́т сезгə́! Ə́йдəгез табы́н янына́ у́тырыгыз.

3) – Исə́нмесез, мөмки́нме?
– Ə́йдəгез ке́регез, у́тырыгыз, чи́шенегез. Монда́ элге́ч (вешалка) бар.
– Рəхмə́т.

4) – Ни́нди мату́р табы́н!
– Ə́йдəгез чəй э́чегез! Нə́рсə белəн эчə́сез?
– Лимо́н белəн.
– Ме́нə өчпочма́к а́лыгыз.
– Ни́нди тəмле́ өчпочма́к!
– Ə́йдəгез та́гын (ещё) чəй э́чегез.
– Рəхмə́т, би́к тəмле́ булды́.

5) – Без китə́без. Сездə́ би́к күңелле́ булды́.
– Та́гын ки́легез.
– Рəхмə́т.

6) – Ə́йдəгез уйны́йбыз!
– Мин Оле́г белəн ша́хмат уйны́йм.
– Ə без җырлы́йбыз.

**6.** Составьте сценарий «День рождения» и разыграйте его.

**7.** Впиши в клеточки названия продуктов и узнай, что сварила мама.









## 131–133 нче дәресләр

**1.** Текстны укы. Бәйрәм белән котларга өйрән.

### 8 нче Март – әнилә́р бәйрәме́!

8 нче Март – яз бәйрәме́, әнилә́р бәйрәме́, әбилә́р бәйрәме́, кызла́р бәйрәме́!



Бу көнне́ һә́ркем бүлә́к әзерли́. Балала́р – әниләргә́, әбиләргә́, апаларга́, әтилә́р – әниләргә́, малайла́р кызларга́ бүлә́к бирә́.

Бүлә́к төрле́ була́. Энә́ дә бүлә́к, дөя́ дә бүлә́к, дилә́р (говорят).

Мин әнигә́ булыша́м: гөлләргә́ су́ сибә́м, савы́т-саба юа́м. «Бу зу́р бүлә́к!» – ди әни́. Әни́ белән табы́н әзерли́без – бу да зу́р бүлә́к. Котла́у язу́ да би́к зур бүлә́к. Мин әнигә́ ме́нә ни́нди котла́у язды́м:

«Кадерле́ әние́м!

Сине́ 8 нче Март бәйрәме́ белән котлы́йм! Сиңа́ озы́н гоме́р, сәламәтле́к, шатлы́к, зур уңышла́р тели́м!

Улы́ң Сама́т».

**бүлә́к** – подарок
**энә́** – иголка
**булышу́** – помощь
**дөя́** – верблюд

**2.** Бу сүзләрне дөрес укыдыңмы?

Озын [ŏзŏ́н], шатлык [ша°тлы̆́к], гомер [ғөмө́р], сәламәтлек [сәләмәтлə̆́к], уңышлар [уңы̆шла́р].

**3.** Кем кемгә бүләк бирә?

Малайла́р – ... .
Балала́р – ... .
Әтиләр – ... .
Кызла́р – ... .

**4.** Рәсемгә кара һәм әйт: син бу бүләкләрне кемгә бирәсең?










**5.** Рәсемнәр урынына сүзләр куй, дустың белән сөйләш.

– Син ке́мгә бүлә́к бирә́сең?
– Әнигә́, апагá. Ә син?
– Мин дә әнигә́, апагá бүлә́к бирә́м.
– Нә́рсә бүлә́к итә́сең?
– Әнигә́ , апагá .
– Ә син нә́рсә бүлә́к итә́сең?
– Мин дә әнигә́ , ә апагá .

**6.** Нокталар урынына җөмләләр куй. Дустың белән сөйләш.

– Айда́р, син ка́я бара́сың?
– ... .
– Ә ни́нди бәйрә́м?
– ... .
– Сез бәйрәмдә́ ни́шлисез?
– Әниләргә́ конце́рт куя́быз. Ә син ни́шлисең?
– ... .

**7.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне, кушымчаларны куеп яз.

8 нче Март – б...йр...м к...н. Мин әни..., әби..., сеңлем... бүлә́к әзерләде́м. Әни... ш...г...рь язды́м. Укытучы́ апа... чәчәклә́р бир... .

**8.** Укытучыңа 8 нче Март бәйрәме белән котлау яз.

## 134–136 нчы дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

| **Кем?** | **Ке́мгә?** |
|---|---|
| апа́ – ул (она) | апага́ – аңа (ей) |
| Илда́р – ул (он) | Илдарга́ – аңа (ему) |

**2.** Фигыльләрне үткән заманда (в прошедшем времени) әйт.

| | | |
|---|---|---|
| әйтә́ – әйтте́ | керә́ – ... | утыра́ – ... |
| тукты́й – ... | ди – ... | бара́ – ... |

**3.** Хикәяне укы. Илдар нинди малай?

### Трамвайда́

Трамвайда́ кеше́ кү́п иде. Алдагы́ урынна́р балала́р һәм картла́р өчен.

Илда́р да бер урынга́ утырды́. Трамва́й туктады́. Вагонга́ кечкенә́ бала́ белән бер апа́ керде́. Ул я́к-ягына карады́, лә́кин буш уры́н кү́рмәде. Илда́р аңа́ уры́н бирде́:

– Апа́, ки́легез, у́тырыгыз, – диде́. Апа́ Илдарга́ рәхмә́т әйтте́.

– Кү́р, улы́м, ни́нди яхшы́ мала́й. Улы́м, си́н дә яхшы́ мала́й бул, – диде́ апа́.



**уры́н** – место **кү́рмәде** – не увидела

**4.** Бу сүзләрне дөрес укыдыңмы?

Алдагы [а°лдағы́], як-ягына [йа́°қ йа°ғына], туктады [туқтады́], утырыгыз [у́тырығыз], карады [қа°рады́].

**5.** Сорауларга җавап бир.

1) Вагонга́ кем керде́?
2) Илда́р ни́шләде?
3) Илда́р нә́рсә диде́?
4) Апа́ Илдарга́ нә́рсә әйтте́?

**6.** Җөмләләрне тәрҗемә ит.

В трамвае было много народу. Трамвай остановился. Ильдар уступил место тёте. Тётя сказала Ильдару спасибо.

**7.** Түбәндәге җөмләләргә сораулар куй.

1) Вагонга́ кечкенә́ бала́ белән бер апа́ керде́.
2) Апа́ Илдарга́ рәхмә́т әйтте́.

**8.** Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куеп, дәфтәреңә яз.

К...чк...нә б...л... б...л...н б...р апа́ к...рд... . Илда́р апа...а ур...н б...рд... . Апа́ Илда́р...а р...хм...т әйтте́. Илда́р – яхш... мала́й.

**9.** Җөмләләрне дәвам ит.

1) Илда́р нача́р мала́й түгел, чө́нки ... .
2) Илда́р тәрбияле́ мала́й, шуңа́ күрә ... .

## 137–140 нчы дәресләр

**1.** Бу сүзләр кайсы рәсемгә туры килә?

Бер алма́, ярты́ алма́, орлы́к, алмага́ч.






**2.** Сүзләрнең антоним парларын тап, дәфтәреңә яз.

кечкенә́ – ...     тәрбияле́ – ...
тәмле́ – ..     яхшы́ – ...
баллы́ – ...     акыллы́ – ...

**3.** Үрнәк буенча тәрҗемә ит.

Үрнәк: его (её) мама – аның әнисе
его (её) папа – ...
его (её) бабушка – ...

их мама – аларның әнисе, аларның әниләре
их папа – ...
их бабушка – ...

**4.** **Исеңә төшер!**

| | |
|---|---|
| **Ке́мне?** – Кого? | **Нә́рсәне?** – Что? |
| әтине́, малайны́ | чәчәкне́, алманы́ |

**5.** Рәсем урынына сүзләр куй. Җөмләләрне укы.

Мин ярты́ алманы́  куйды́м.
Мин ярты́ алманы́ алды́м.

**6.** Бу сүзләрне дөрес укыйсыңмы? Аларның тәрҗемәсен сүзлектән кара.

Алма [а°лма́], татлы [та°тлы́], сәгать [сәға́т], ярты [йа°рты́], орлыклар [ŏрлŏкла́р], бакчага [ба°қчаға́].

**7.** Хикәяне укы. Сиңа кайсы малай ошый?

### Өч ул

Бер кешене́ң өч улы́ ба́р икән. Кечкенә́ малайны́ң исеме́ – Гали́. Әтиләре́ базарда́н өч алма́ алы́п кайтты́. Алмала́р би́к тәмле́, татлы́.



Бе́рничә (несколько) сәга́ть үтте́. Әтиләре́ малайларда́н: «Алмаларыгы́з ка́йда?» – дип сорады́.

– Әти́, мин алманы́ ашады́м. Орлыкларны́ бакчага́ чәчте́м, – диде́ олы́ мала́й.

– Яхшы́, улы́м, – диде́ әтисе́.

– Мин дә алманы́ ашады́м, сиңа́ рәхмә́т әйтте́м, – диде́ икенче́ мала́й.

– Яхшы́, улы́м, – диде́ әтисе́.

– Әти́, мин ярты́ алманы́ ашады́м, – диде́ Гали́.

– Ә ярты́ алма́ ка́йда? – диде́ әтисе́.

– Мин аны́ Вәлигә́ бирде́м, чө́нки ул авырый́.

– Би́к яхшы́ булга́н, улы́м, – диде́ әтисе́.

Дәрдемәндтә́н

**8.** Нокталар урынына тиешле сүзләрне куй, дәфтәреңә яз.

1) Беренче малай алманы … . 2) Икенче малай алманы … , әтисенә рәхмәт … . 3) Өченче малай ярты алманы … , ярты алманы Вәлигә … .

**9.** Диалогны укы. Дустың белән сөйләш.

– Әни́, мин Ка́тяларга бара́м.
– Ни́гә (почему)?
– Ул авырый́й.
– Ка́тяга нә́рсә ала́сың?
– Алма́, сок ала́м.
– Ярый́й, кызы́м, би́к яхшы́.

## 141–142 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Вспомни рассказ «Трамвайда». Составь рассказ, схожий по содержанию.

**2.** «Өч ул» хикәясен дустыңа сөйлә.

**3.** Как скажешь, что:

– ты всегда уступаешь место дедушкам, бабушкам;
– взрослые говорят тебе спасибо?

Запиши эти предложения в тетрадь.

**4.** Син телефоннан сөйләшә беләсеңме? Диалогларны укы, иптәшең белән сөйләш.

1) – Алло́, Альби́на апа́, исә́нмесез! Бу мин – Оле́г. Ә Мара́т өйдә́ме?
– Өйдә́.
– Маратны́ ча́кырыгыз әле.

2) – Алло́, Сания́ апа́, исә́нмесез! Сезне́ Ле́на борчы́й. Миңа́ Алсу́ кирә́к иде.

– Алсу́ өйдә́ юк әле.

– Ә ка́йда?

– Трениро́вкада.

– Ярый́, рәхмә́т. Са́у булыгыз!

**5.** Пригласи друга сесть за стол и угости его чаем, тортом.

**6.** Ты был в гостях, и тебя угостили вкусными пирогами. Как поблагодаришь хозяев?

**7.** Твой друг Саша в автобусе уступил место бабушке. Какой он мальчик? Расскажи об этом маме.

**8.** Как скажешь, что:

– в автобусе свободных мест не было;
– ты уступил место дедушке;
– дедушка сказал спасибо?



# КЕЧКЕНӘ ДУСЛАРЫБЫЗ



## 143–145 нче дәресләр

**1.** **Исеңә төшер!**

| | |
|---|---|
| **Кем?** – Кто? | **ул** – он, она |
| **Ке́мне?** – Кого? | **аны́** – его, её |
| **Ке́мгә?** – Кому? | **аңа́** – ему, ей |

**2.** Поставь вопросы к выделенным словам. Переведи предложения.

1) Мин **аны́** ярата́м. 2) Син **аңа́** чәчә́к бирә́сеңме? 3) Әни́ **аны́** көтә́. 4) **Аңа́** ун яшь.

**3.** Диалогларны сөйләшергә өйрән.

а) – Син ке́мне ярата́сың?
– Мин әнине́, әтине́ ярата́м.

ә) – Бу ке́м?
– Бу – А́ня.
– Син аны́ ярата́сыңмы?
– Әйе́, мин аны́ ярата́м.

б) – Бу нә́рсә?
– Бу – Акба́й.
– Син аны́ ярата́сыңмы?
– Әйе́.

**4.** Нокталар урынына кушымчаларны куеп, җөмләләрне яз.

1) Аза́т урам... чыкты́.
2) Аза́т урам... уйны́й.
3) Аза́т урам... өйгә́ керде́.

**5. Исеңдә калдыр!**



**кө́н саен, һә́р көн** – ежедневно, каждый день

**атна́ саен, һә́р атна** – еженедельно, каждую неделю

**е́л саен, һә́р ел** – ежегодно, каждый год

**6.** Җөмләләрне тәрҗемә ит.

1) Я каждый день выхожу на улицу. 2) Дети каждое лето отдыхают в лагере. 3) Мы каждую неделю ходим в лес.

**7.** Сораулар ярдәмендә сүзләрне төрләндер.

| **Кем?** | **Ке́мгә?** | **Ке́мне?** |
| --- | --- | --- |
| Кәри́м | ... | ... |
| ул | ... | ... |

**8.** 7 нче күнегүдәге сүзләр белән җөмләләр төзе.

**9.** Сүзләрнең тәрҗемәсен сүзлектән тап.

| | | |
| --- | --- | --- |
| терелде́ – ... | ни́ндидер – ... | тәпи́ – ... |
| өрә́ – ... | саклы́й – ... | янәсе́ – ... |
| хуҗа́ – ... | авыртá – ... | ти́мә – ... |

**10.** Тәрҗемә ит.

Этém, минém этém, этемнéң тәпиé, этемнéң тәпиләрé.

**11.** Хикәяне укы.

## Дусла́р



Кәримнéң этé бар. Аны́ң исемé Актырна́к. Кәри́м аны́ би́к ярата́. Актырна́к та Кәримнé би́к ярата́. Бéрвакыт Актырнакны́ң тәпиләрé авырта́ башлады́. Кәри́м гел аны́ң янында́ булды́. Ул Актырнакка́ көн саен ипи́, аш бирдé. Актырна́к терелдé.

Бéрвакыт ул Кәри́м белән бергә́ урамга́ чыкты́. Мéнә ни́ндидер эт Кәримгә́ өрә́ башлады́. Актырна́к та эткә́ өрдé. Янәсé (будто):

– Син минéм хуҗама́ ти́мә. Ул минéм дусты́м. Мин аны́ ярата́м һәм саклы́йм.

Мәрья́м Галлә́мовадан

## 146–147 нче дәресләр

**1.** Найди в тексте «Дуслар» предложения о том, что:

– у собаки болит лапа;
– Карим любит собаку;
– Карим ежедневно ухаживает за собакой;
– собака поправилась;
– Актырнак защищал своего хозяина.

**2.** Нокталар урынына **чөнки, шуңа күрә** сүзләрен куеп яз.

1) Актырнакны́ң аяклары́ авыртá, ... ул ашáмады.
